| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ШАРЛИАРЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

**от 20.03.2024г.** **№ 1**

«Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясына туры китереп, Шәрләрәмә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТӘ:**

1.2024 елның 30 мартында 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Сөлек торак пункты, Мәктәп урамы, 56 йорт адресы буенча урнашкан Сөлек авылы клубы бинасында «Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Шәрләрәмә авыл җирлеге Сөлек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Сөлек торак пунктында электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр

энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру), трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау;
2. Сөлек торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);)
3. торак пункт территориясен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторына ГСМ сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу);
4. Сөлек торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу);»;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Шәрләрәмә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районының
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы /Н.Н.Хуҗина/